**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» Указына үзгәрешләр керту хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-196 номерлы һәм 2016 елның 11 мартындагы ПУ-236 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия турында нигезләмәнең 1 пункты икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана. Комиссия составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкилләре, Татарстан Республикасы иҗат берлекләре җитәкчеләре, шулай ук башка затлар керергә мөмкин.»;

б) Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан В.П. Аршиновны, Р.Х. Корбановны, В.П. Логиновны, А.М. Сибагатуллинны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Камалова Эльвира Рафаил кызын – Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасарын, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Кудряшев Владимир Николаевичны – «Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге» иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисен (килешү буенча);

Салихов Данил Хәбибрахман улын – «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» (иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы рәисен (килешү буенча);

Сираҗиев Илнур Ильбрус улын – «Россия Рәссамнар берлеге» бөтенроссия иҗтимагый иҗади оешмасының төбәк бүлекчәсе «Татарстан Рәссамнар берлеге» идарәсе рәисен (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 21 апрель
№ ПУ-329